**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлегенең Бәли торак пунктындагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**2020 ел 13 ноябрь** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законының 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 12 ноябрендәге 14 сәгать 00, 2020 елның 13 ноябрендәге 13 сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплап җыеннары нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, "Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлегенең Бәли торак пункты территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?":

**а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- торак пунктлар территорияләрен чистарту;

**б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:**

- материаллар алу белән су челтәрләрен ремонтлау

- су алу скважиналарын лицензияләү буенча әзерлек эшләре ( гигиена һәм эпидемиология үзәге федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениясендә суны анализлау, " Санитар саклау зоналары" һәм "Эчәр су" зоналарында СанПин нормаларына экспертиза уткәрү, санитар – эпидемиология нәтиҗәсе алу);

**в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

- материаллар сатып алынган юлларны норматив хәлгә китерү

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

« РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре беркетмәсе буенча:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 127 гражданнар җыенында катнашучылар кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 76 кеше, бу 56 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 76 "РИЗА" позициясе өчен, 0 "КАРШЫ" позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены хэл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлегенең Бәли торак пунктындагы гражданнар җыенын үткән дип, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. "2021 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге Бәли торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган һәрбер кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?

***а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру*:**

- җирлектэге торак пунктлардагы чүплекләрне чистарту;

***б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:***

- материаллар сатып алып, су челтәрләрен ремонтлау;
- су алу скважиналарын лицензияләү буенча әзерлек эшләре ( гигиена һәм эпидемиология үзәге федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениясендә суны анализлау, “ Санитар саклау зоналары” һәм “Эчәр су” зоналарында СанПин нормаларына экспертиза уткәрү, санитар – эпидемиология нәтиҗәсе алу);.

***в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:***

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- җирлекнең торак – пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

3. “Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлегенең Бәли авылында халык җыены нәтиҗәләре турындагы” 2020 елның 13 ноябрендәге 1 номерлы халык җыены карарын гамәлдән чыгырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек
Колангы авыл жирлеге башлыгы итүче Ф.Т.Нигматзянов